**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел,3 март №19

**Чүри-Бураш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Чүри-Бураш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чүри-Бураш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 февралендә кабул ителгән 27 нче номерлы «Чүри-Бураш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы» карарының Чүри-Бураш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә дип исемләнгән 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.23 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.23. класс чинын муниципаль хезмәткәргә бирү турындагы белешмәләр муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә һәм хезмәт кенәгәсенә (булган очракта) кертелә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 5.6.1 пункт өстәргә:
«5.6.1. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында аларның тиешле вазыйфасын биләгән чорында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

4) 15.10 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәләре, шулай ук муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 30 статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре кирәк булганда.»;

4) 16.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«16.5. Муниципаль хезмәт стажын раслый торган төп документлар - билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр.»;

5) 16.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«16.7 Хәрби хезмәт узу чоры, аңа тиңләштерелгән башка хезмәт узу чоры, шулай ук салым полициясенең федераль органнары, таможня органнары хезмәткәрләренең хезмәт узу чорлары хәрби билетлар, хәрби комиссариатлар, хәрби бүлекчәләр, архив

учреждениеләре белешмәләре, хезмәт кенәгәсендәге язмалар һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, хезмәт исемлекләре белән расланырга мөмкин.»;

6) 20.8 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә гражданның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (элек хезмәт (хезмәт) эшчәнлеге башкарылмаган очраклардан тыш);».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүри-Бураш авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Чүри-Бураш авыл җирлеге**
**Башлыгы,**
**Чүри-Бураш авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **И.Р. Мифтахов**